## ЯШЬЛЕК АВАЗЫ

Ялкын йөрәкле яшьләр без,
Яшендәй яшьнәп яшәр.
Чорның яңгырар авазы
Көрәшкә, алга дәшә.
Тынгысыз хыял, дуслыкны
Байрагы итә яшьләр!
Безнең җанның кайнарлыгы
Йөрәктән күчеп хискә —
Я ҚамАЗга әверелә,
Я шәһәр булып үсә...
Күкләрдән иңгән түгел бу,
Күкрәүдән килгән хәбәр.
Бүгенгә бездән һәйкәл ич
Үзебез төзегән ҚамАЗ,
Үзебез салган шәһәр!..

**Ямаш Игәнәй**

© Татарстан китап нәшрияты, 1983.

## ЗАМАН БЕЛӘН БЕР САФТА

Ун ел вакыт эчендә Брежнев шәһәрендә ҚамАЗның гигант корпуслары белән янәшә тагын бер цех — күрер күзгә күренмәс әдәби цех күтәрелде. Бу цехның хезмәт җимешләре югары бәяләнде, һәм, 1980 елның январь аенда РСФСР Язучылар союзы идарәсе карары белән, шәһәрдә беренче профессиональ иҗат союзы — Брежнев язучылар оешмасы барлыкка килде.

Бу яклар иҗат көчләренә бай төбәк — унбер СССР Язучылар союзы члены булуы, тагын ике кешенең союзга тәкъдим ителүе шул хакта сөйли. Биш яшь язучы — Горький исемендәге әдәбият институты студентлары, төбәктәге әдәби-иҗат берләшмәләрендә ике йөзләп кеше әдәбият серләрен өйрәнә. Шушы якта иҗат итүче СССР Язучылар союзы члennары һәм яшь авторлар җитмештән артык китап бастырдылар. Алар арасында Кама буендагы хезмәт батырлыгына багышланганнары аерым урын тота. Әдәбиятны пропагандалауга, яшьләрне эстетик тәрбияләүгә керткән өлешләрен дә санасаң, төбәктәге язучыларның актив тормыш позициясендә торуларын аңларга була. Культура сарайларында, клубларда уздырылып килә торган кичәләрнең әдәбият сөючеләргә генә түгел, авторларга да файдасы зурлыгын тоясың.

Әлбәттә, безнең моңа кадәр язылган әсәрләребез — зур әдәбиятка беренче адымнар гына. Дөньяны үз җилкәсендә тотып торучы хезмәт кешесенең омтылышларын, рухи халәтен, хыял-чынбарлыгын сурәтләвебезнең язылачак әсәрләребез өчен төп тема булырга тиешлеген истән чыгармаска кирәк. Кешенең җәмгыятьтә тоткан урынын, бәхетен бары тик хезмәттәге эшчәнлеге белән бәйләп яктырту — бүгенге көндә безнең төп бурычыбыз менә шуннан гыйбарәт.

Кама автогигантының продукциясе бик тиз арада киң танылды һәм дан алды. Бу — Брежнев шәһәре кешеләренең мактанычы. Алай гына да түгел, «ҚамАЗ» — республикабызның, илебезнең мактанычы. Әмма без — әдәбият әһелләре — машиналарның салкын тимерләренә йөрәк җылысын салучыларны әлегә шактый саран сурәтлибез. Кайчакта әле безнең кайбер яшь язучыларыбыз «ҚамАЗ» машинасының куәтле двигательләре тарту көченә ышанып баручы пассажирларны хәтерләтәләр. Безгә әдәбиятның канатлы атында «ҚамАЗ» машиналарына юл күрсәтеп алдан барырга вакыт җиткәндер.

Әдәбият һәм сәнгать эшчәннәренә партия тарафыннан йөкләнгән бурычларның иң зурысы — кешене коммунистик рухта тәрбияләү. Яңа социаль шәхес — бөек төзелешләрдә катнашучы герой елдан-ел катлаулана бара. Аның хезмәткә мөнәсәбәте, үз-үзенә таләпчәнлеге

югарырак, культурасы һәм белеме тирәнрәк. Бары шундый геройлар гына очерк-хикәяләргә, роман-повестьларга керә ала. Әлбәттә, аның җанына үтеп керү, аны художество биеклегендә сурәтләү язучыдан күп хезмәт һәм талант сорый. Әдәби иҗатчыларның камазлылар белән әйбәт багланышта торуы, очерк-публицистикада хезмәт казанышларының яктыртылуы турында сөйләсәк тә, бүген инде бер нәрсә ачык — рейдлар, иҗади командировкалар, «күчмә редакция»ләр аша безгә камазлылар һәм язучыларның күпъеллык иҗади һәм үзара дуслыгына күчәр вакыт җиткән. Бөек төзелеш кешеләре һәм эшләре турында шигъри цикллар, поэмалар, драмалар, роман-повестьлар язу — безнең намус эшебез. Фән-техника революциясенең тирән пафосын алга киткән социализм шартларында тасвирлау, масштаблы-художестволы гомумиләштерү өчен бездә бөтен мөмкинлекләр дә бар.

Каләм осталарының хуҗалык һәм культура төзелешендә катнашуы, шуның нәтиҗәсендә сәнгать һәм хезмәт бердәмлегә барлыкка килүнең формалары күп төрле. Производство белән язучыларның дуслыгы ныгый һәм көчәя бара. Моннан берничә ел элек «Камгэсэнергострой» берләшмәсе һәм язучылар оешмасы арасында хезмәттәшлек килешүе төзелде. Бу хезмәттәшлекнең девизы: «Хезмәт һәм әдәбият бердәмлеге ныгысын!» Ә нәтиҗәсе — очерклар, хикәяләр, публицистик чыгышлар, җырлар. Хәзер әлеге зур коллективның яшь төзүчеләренә багышланган повесть языла.

КамАЗның беренче нигез ташыннан башлап беренче автомобиленә кадәр араны үз күзләре белән күрен, үз йөрәкләре аша үткәреп яшәгән кешеләр, өчен Брежнев шәһәре аерата зур мәгънәгә ия, аерата кадерле.

Ел үсәсен көн үсеп, үз әти-әнисенең кочагына сыймый башлаган шәһәр-баһадир алдында күпләребез башта бер мәлгә телсез калган сыман булдык. Аның белән аңлашу өчен аның биеклегендә торып сөйләшергә, аның күңеленә үтеп керү өчен аның уй-хисләрен, аның бүгенге халәтен һәм киләчәген бөтен җаның белән тоярга кирәк иде.

Инде белгәнебезчә, КамАЗның төп продукциясе зур йөк автомобильләре булса, аның асыл продукциясе — кешеләр. Кыска гына вакыт эчендә КамАЗ үз тирәсенә ничә меңгә якын кешене туплады. Ничә мең проблема, ничә мең язмыш... Менә шул проблемаларны чишү, хәл итү, шул язмышларны үз ярына — КамАЗ ярына кертү автомобиль заводы салудан һич тә гадирәк нәрсә түгелдер.

КамАЗга моннан дистә ел чамасы элек нигез ташы салынган булса, шәһәр язучылар оешмасының нигезе инде күп элек корыла башлаган иде. Алтмышынчы еллар башында ук «Коммунизм байрагы» газетасы каршында оешкан әдәби берләшмә гөрләп эшләгәндә, аңа йөрүче яшь шагыйрьләрнең, прозаикларның әсәрләре республика матбугаты аша инде күпләргә билгеле булган чакта, районга — Тукай районы, ә шәһәргә Брежнев шәһәре исеме бирелүдән күп еллар элек, Чаллы басулары әле үз иңнәренә нинди йөк төшәсен сизмичә-белмичә тугарылып ята иде. Ләкин бу әдәби берләшмәнең ныклап аякка басып, язучылар оешмасы булып өлгерүе өчен зуррак мәйдан, зуррак масштаблар кирәк булган икән.

КамАЗ төзелә башлауга, бирегә, йөзләгән профессия кешеләре белән бергә, төрле яклардан романтик кү-

целле, шагыйрь җанлы кешеләр дә җыйналды. Хәниф Хөснуллин, Сәлимә Шәрипова, Мөслах Таҗи, Рафис Хисамиев кебек өч дистәгә якын шагыйрь һәм прозаикны туплаган әдәби берләшмәгә Мәхмүт Газизов, Равил Вәлиев, Газиз Кашапов, Рәшит Бәшәров, Равил Лотфуллин, Рафис Сәлимҗанов, Ямаш Игәнәй, Альберт Сафин һәм тагын дистәләгән яшь иҗат көчләре килеп кушылды. «Ләйсән» берләшмәсе белән янәшә рус язучыларының «Орфей» әдәби берләшмәсе оешты.

КамАЗ проблемаларын, аларның республика һәм ил тормышына, кешеләр язмышына ни дәрәҗәдә кагылышлы икәнен аңлау һәм аларны югары сәнгать дәрәҗәсендә бәян итү өчен әле шактый хезмәт тә, вакыт та кирәк булачак. КамАЗ турында әле моңа кадәр язылган әсәрләр, юл яручылар буларак зур әһәмияткә ия булсалар да, зур таләп белән караганда, бер бөртек түгәрәк ипине сабый баланың йомшак тешләре белән кыр-кырыеннан кимерүен хәтерләтә сыман.

Брежнев язучылар оешмасының төп бурычы — әдәби көчләрне бер тирәгә, бер гвардиягә туплап, аларга юнәлеш бирү, бергәләп әлегә теш үтмәгән проблемаларны аңларга һәм, йөрәк аша үткәреп, кешеләргә аңлатырга омтылу, яшь иҗат көчләренә үз юлларын табарга булышу һәм халык белән әдәбият-сәнгать осталары арасындагы элемтәне ныгытудан гыйбарәт. Инде әйткәнемчә, КамАЗда әдәбият көчләренең зур армиясе тупланган.

КамАЗ проблемалары, шәһәр кешеләре турында инде шактый әсәрләр язылды. «Үз язучыларыбыз» әсәрләре янында «Новый мир» журналының махсус рубрикасында чыккан әдәби очеркларны, Мәскәү һәм Казан язучыларының КамАЗ «заказы» белән иҗат ителгән хикәя, повесть һәм романнарын, шигырь һәм поэмаларын да кушып исәпләгәндә, «әдәбият цехы» конвейерының продукциясен шактый ачык күзалларга була. Ләкин КамАЗ масштабларына тәңгәл әсәр әле һаман да язылмаган, КамАЗ — баһадир язучылардан үзенә тиң әсәрләр көтә.

Бездә күтәрелгән проблемаларның фәнни үзләштерелүе, әдәби осталыкны күтәрү хакында сүз еш була. Брежнев язучылары өчен бу аеруча мөһим. Язучылар оешмасы әле көч кенә җыя, бөтен өмет яшьләргә баглана. Соңгы вакытта язучылар коллективын ныгытуга, иҗади активлыкны көчәйтүгә игътибар артты. Партиябезнең XXVI съезды, СССР язучыларының VII съезды куйган иң мөһим мәсьәләләргә язучыларның игътибарын юнәлтүгә язучылар оешмасы зур эшләр башкара һәм станоклардан әдәби тормышка килүчеләрне тиешле юлга юнәлтә. Безнең үз язучыларыбыздан туган як һәм аның кешеләре турында тирән, үзенчәлекле һәм кызыклы әсәрләр көтәргә хакыбыз бар, чөнки алар үз халкын, туган җирне әйбәт беләләр. Алар арасында сәләтле яшьләр күп, ә яшьләрнең киләчәге алда.

Бер язучыбыз: һәр сугыш үзенең хәрби эшлеклеләрен һәм елъязмачыларын тудыра, бу сугыш турында бары тик алар гына яза ала, дигән иде. Чыннан да шулай булды. Бөек төзелешләрнең, бөек эшләрнең дә үз полководецлары, үз елъязмачылары булыр дип ышандырасы килә.

Брежневка беренче килгән кешенең күзенә урамдагы кешеләр агымының яңа төсмерләре ташлана. Дистә ел элек бу агым төрле төстә-

ге эш киемнәреннән тора иде. Ләкин алмашка яңа көн килә: һәм шәһәр кешесенең үз-үзен тотышы, кием-салымы, йөреше үзгәрә. Тышкы культура кешенең рухи культурасына да күчә. Күзгә ташланган икенче билге — «дипломат» тоткан студент, мольбертлы рәссам, скрипкалы музыкант, әдәбият яңалыклары турында бәхәсләшүче яшь шагыйрьләр. Әйе, автошәһәрдә иҗат интеллигенциясе үсте һәм бу үсеш киләчәктә көчәячәк кенә. Димәк, иҗат кешесенә шәһәр яңалыкларын, андагы күркәм эшләрне сурәтләргә уңайлы шартлар булдыру турында уйларга кирәк.

Җае чыкканда шуны әйтәсе килә, соңгы вакытта партиянең шәһәр комитеты Брежнев халкының рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә зур игътибар бирә. Музейларның җанлануы, художество күргәзмәләренең күбәюе, яңа үзешчән коллективларның артуы шуны күрсәтә.

Шулай да яшь буын турында әле тагын да ныграк кайгыртырга кирәк. Алар бирелә күп. Давыллы фән-техника прогрессы аларның эстетик үсешләрен күмеп китмәсен. Шәһәребезнең сәнгате һәм әдәбияты аларга барлык эшләнгән эшләрен бәһаләп, вакытны һәм үз-үзен аңларга, никсез Ватаныбыз картасына «Брежнев» дип язылган төбәкне аңларга һәм яратырга хезмәт итсен иде.

**Разил Вәлиев,**

Брежнев язучылар оешмасының җаваплы секретаре